| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.06. 2019 ел Баулы шәһәре №162

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2011
елның 19 апрелендә кабул ителгән
107нче номерлы карары белән
расланган Төзелешкә рөхсәт бирү
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Хекүмәтенең 2017 елның 31 гыйнварында кабул ителгән 147-р номерлы (2019 елның 19 апрелендәге редакциядә) «Бизнес алып бару процедураларын гадиләштерүнең һәм Россия Федерациясе субъектларының инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыруның максатчан модельләре турында»гы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 19 апрелендә кабул ителгән 107нче номерлы карары белән расланган Төзелешкә рехсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

2нче «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

- 2.3 пунктта икенче баганада түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (uslugi.tatarstan.ru) аша гариза биргәндә муниципаль хезмәт нәтиҗәсе электрон формада бирелә.»;

- 2.4 пунктта «җиде эш кене» сүзләрен «биш эш кене»нә алмаштырырга;

- 2.5 пунктта.:

1нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) гариза (Регламентка 1нче кушымта):

- документ формасында кәгазьдә;

- электрон формада (искәрмә: мерәҗәгать итүче исеменнән эш итүче затлар), «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендә кабул ителгән №63-ФЗ Федераль закон (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм «Дәүләт һәм муниципаль

хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендә кабул ителгән 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы (uslugi.tatarstan.ru) аша имзаланган.

Гаризага теркәлә:

а) мерәҗәгать итүченең шәхесен яки аның идентификация һәм аутентификацияләүнең бердәм системасыннан (алга таба-ЕСИА) алынган реквизитларын раслаучы документ (стандарт хисап язмасыннан (электрон форма тутырганда) ким түгел);

б) мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен раслаучы документ яки аның скан-күчермәсе (электрон форма тутырганда).»;

4 нче пунктчада):

"проект документларында булган материаллар» сүзләре алдыннан «инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре һәм башкалар" сүзләрен язарга (2019 елның 1 июленнән үз көченә керә);

б), в), г) абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә (2019 елның 1 июленнән үз кеченә керә.):

«б) шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә җир кишәрлеген планлаштыру схемасы, территорияне планлаштыру проекты нигезендә башкарылган бүлеп бирелгән полоса проекты (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен документация эзерләү кирәк булмаган очраклардан тыш);

в) архитектура белән бәйле һәм конструктив карарлар, шулай ук инвалидларның капиталь тезелеш объектына керә алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән карарлар һәм чаралар урын алган бүлекләр (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм социаль-мәдәни һәм коммуналь-кенкүреш билгеләнештәге башка объектлар, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектлары, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектлар, торак фонды объектларына проект документлары әзерләнгән очракта);

г) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты (капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен төзү, реконструкцияләү ечен капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтүне оештыру белән бәйле проектны да кертеп).»;

д), ж), з) абзацларын тешереп калдырырга (2019 елның 1 июленнән үз көченә керә);

- 2.8 пунктта икенче баганада түбәндәге эчтәлекле 5нче абзац естәргә:

"5) №63-ФЗ һәм №210-ФЗ Федераль законнары таләпләре нигезендә кул куелмаган гариза һәм документлар (документлар күчермәсе) тапшыру (электрон формада гариза биргәндә)»;

- 2.15 пунктның икенче баганасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы (uslugi.tatarstan.ru) шәхси кабинет аша гариза бирү, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат, муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен алу мөмкинлеге;

Башкарма комитет яки күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренә кабул итүгә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша (uslugi.tatarstan.ru) язылырга мөмкин (техник мөмкинлекләр булганда)»;

- 2.16 пунктта икенче баганада түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Муниципаль хезмәт түбәндәге очракларда электрон формада күрсәтелә:

- әгәр капиталь төзелеш объектының проект документларына экспертизаның уңай бәяләмәсе (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба – РФ ГК) 48 ст.12.1нче частендә каралган очракта, төзелешнең аерым этапларына карата), РФ ГК 49 ст. 3.4нче частендә каралган очракта, проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, РФ ГК 49 ст. 6нчы частендә каралган очракта, проект документларына дәүләти экологик экспертиза уңай бәяләмәсе электрон формада бирелгәндә (электрон-цифрлы имза белән расланган);

- әгәр капиталь төзелеш объектының проект документлары һәм (яки) мондый проект документларын әзерләү өчен башкарылган инженерлык эзләнүләр нәтиҗәләре, шулай ук проект документларына һәм (яки) инженерлык эзләнүләр нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрү өчен кирәкле башка документлар электрон формада тәкъдим ителгән булса.

Мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документ яки ЕСИАдан алынган стандарт хисап язуыннан (электрон форманы тутырганда) ким булмаган реквизитлары.

Муниципаль хезмәт күрсәтүгә электрон формадагы гариза 63-ФЗ номерлы, 210-ФЗ номерлы Федераль законнар таләпләренә туры китереп гади электрон имза белән имзалана.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы (uslugi.tatarstan.ru) аша алынган гаризаны теркәү «Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат үзәге» мәгълүмат системасының эчке кулланучылары өчен электрон рәвештә дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмиятле хезмәтләр күрсәтү модулендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы (uslugi.tatarstan.ru) аша гариза биргәндә муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы, шулай ук муниципаль хезмәт нәтиҗәсе турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталындагы (uslugi.tatarstan.ru) шәхси кабинетына җибәрелә, мөрәҗәгать итүченең башкаручы белән турыдан-туры хезмәттәшлеге таләп ителми.»;

«Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү вакыты, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, күпфункцияле үзәкләрнең ерак урнашкан эш урыннарында башкару үзенчәлекләре» 3нче бүлегендә:

- 3.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 3.1.2 пунктча белән тулыландырырга:

«3.1.2. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында (uslugi.tatarstan.ru) электрон формада гариза биргәндә:

1) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында (uslugi.tatarstan.ru) гариза бирүченең гаризаның электрон формасы тутыруы;

2) гариза кабул итү һәм теркәү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм җибәрү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен әзерләү;

5) гариза бирүченең Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталындагы шәхси кабинетына (uslugi.tatarstan.ru) нәтиҗә җибәрү.»;

3.3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.3.1. Гариза бирүче түбәндәге гаризаларны бирә ала:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача, шәхсән яки ышанычлы зат аша һәм документларны әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә бүлеккә җибәрә;

2) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы (uslugi.tatarstan.ru) аша электрон формада.

Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза Бүлеккә Баулы муниципаль районының Интернет-кабул итү бүлеге, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы (uslugi.tatarstan.ru) аша җибәрелә ала. Электрон формада килгән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров